ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 30.11.2020 г. Казань № 318-2/г-2020

2021 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга махсус өстәмә хак күләмнәрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә хаклар билгеләү тәртибе турында» 2001 елның 3 маендагы 335 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлау тарифларына махсус өстәмә хаклар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2011 елның 21 июнендәге 154-э/4 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга барлык кулланучы төркемнәре (халыктан тыш) өчен 2021 елга әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән махсус өстәмә хак күләмнәрен билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
30.11.2020 № 318-2/г-2020
карарына кушымта

2021 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга календарь буенча бүленгән махсус өстәмә хак күләмнәре

| Т/с | Татарстан Республикасының газ бүлү оешмасы исеме | Ел | Махсус өстәмә хак күләме, 1000 куб метр өчен сум (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|---|
| 1. | «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 63,01 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 65,34 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге